# *Гади җөмлә төрләре*

- Баш кисәклəрдән генә торган җөмлә ҖЫЙНАК ҖӨМЛӘ дип атала. Мәсәлән:

*Алсу укый. Кыз яза. Яз җитте. Яңгыр ява.*

- Баш кисәкләрдән башка иярчен кисәкләре дә булган җөмлә - ҖӘЕНКЕ ҖӨМЛӘ дип атала.

Мәсәлән: *Алсу китап укый.*

*Җылы яңгыр ява.* *Ямьле яз җитте.*



# Җөмләнең баш кисәкләре.

- Җөмләнең баш кисәге – ИЯ

Мәсәлән: Кошлар кайтты.

- Җөмләнең баш кисәге – ХӘБӘР

Мәсәлән: Тургай ***сайрый.***

# Җөмләнең иярчен кисәкләре.

- Тәмамлык – *Алсу* **китап** *укый.*
- Аергыч – *Алсу* **кызыклы** *китап укый.*
- Хәл – ***Дәрестә*** *Алсу кызыклы китап укый.*



# Җөмләләргә иярчен кисәкләр өстәгез.

Көз җитте.   Чәчәкләр шиңделәр.

Үләннәр саргайдылар.  Кар ява.

Яңгырлар ява башланды.  Җәй җитте.

# Бирелгән схемалар буенча җөмләләр төзегез.

- ______________ ~~~~~~~~~ - - - - - - - -
- ========== .
- ~~~~~~~~~ _____________ ===========.
- _____________ ~~~~~~~~~ - - - - - - hәм - - - - - - - ==============.
- _____________ -.-.-.-.-.-.-.- да, -.-.-.-.-.-.-.- ===========.